# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге
Мәсгут торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

18 март 2024 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 1 номерлы “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 24.11.2023 елгы 1 номерлы, “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” 24.11.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында” карары нигезендә 2024 елның 18 мартында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде:
“Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 24.11.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 24.11.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:
-Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Лампалар, Яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам яктыртуын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр)ремонтлау;
- Мәсгут торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зиратның коймаларын алыштыру (демонтажлау, монтажлау, панельләр сатып алу));
-Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны грейдер белән тигезләү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 250 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 153.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен – 153, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

Чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп, 24.11.2023 №1 “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында”, 24.11.2023 №2 “2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге Мәсгут торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында” гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертүгә ризамы:

-Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Лампалар, Яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам яктыртуын ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү буенча хезмәтләр)ремонтлау;

- Мәсгут торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү (зиратның коймаларын алыштыру (демонтажлау, монтажлау, панельләр сатып алу));

-Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны грейдер белән тигезләү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Мәсгут авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatar.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районының Мәсгут авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,Азнакай муниципаль районы Мәсгут авыл җирлеге башлыгы: Д.З.Миннеханов